

Әссәламvгаләй кvм, хөрмәтле дин кардәшләр, газиз милләттәшләр, ватандашлар!
Әлхәмдvлилләһ! Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә, сезнен белән, насыйп кылды тагы бер Рамазан шәриф аен каршы алырга!
Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кә- римдә болай боера: «Сездән элек килеп киткән милләтләргә фарыз кылынган кебек ук, Рамазан уразасы фарыз кылынды».
Уразалы  моселманнар  очен шушы газиз айнын һәрбер ифтар кичәсе бәйрәм сымак, диде пәйгамбәребез Мохәммәд (са-лаллаһу галәйһи вәсәлләм).

Ал-лаһнын тыйганнарыннан тыелып, кушканнарын vтәп яшәргә тырышлык куябыз: иманнарыбыз ныгытыла, рухи байлык, коч һәм куәт арта һәм доньяда тагы да яшисе килә, кvп эшләр эшлисе килә - гади халыкка, дәvләткә файда китерәсе килә!

Ләкин, тагы да Аллаһы Тәгаләгә бер торле гыйбәдәт кылу торе турында сезгә әйтәсем килә: «Аллаһ юлында халыкка хезмәт итv vзе бер гыйбәдәт.» Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам болай дигән: «Кем халыкка якын, ул Аллаһка якын...»
Татар халкынын боек шагыйре Габдулла Тукай vзенен «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» шигырендә дә шул ук фикерне шигъри юлларга салып язган.
Хөрмәтле дин кардәшләр, ки- ләсе айларнын солтаны - Рамазан шәриф ае мобарәк булсын! Аллаһы Раббыбыз ураза, таравих намазлар, зәкәт, нәфел сәдакалар һәм

кешеләргә яхшылык белән тыелу аркылы ботен гонаһларыбызнын кичерелvенә сәбәп әйләсен!

Ил - коннәребездә тынычлык һәм иминлек булсын! Дәvләт житәкчеләребезгә: мохтәрәм Президентыбызга, Мор-довия Республикасы Главасына, ватанпәрвәрләребезгә Аллаһы Тә галә дәvләт белән сәяси идарә итvдә зирәк зиһен, камил акыл, кvркәм холык һәм сабырлык бирсен! Боек дәрәжәгә ирешкән фәлсәфә, шәригать гыйлемнәрендә, дәvләт сәясәтендә зур унышларга ирешкән шәхес - Абу Хамид Әл Газали болай әйткән: «Дәvләт һәм дин бертуган шикелле. Дин - кануннарга тозелеп нигезләнгән дәvләттә генә иркәләнеп тарала һәм vсешен арттыра алала.»
Махсус хәрби операция мәй-даннарында вафат булган дин кардәшләребезгә - батырларыбызга, каһарманнарыбызга, пәһ- леваннарыбызга Аллаһы Тәгалә шәһидләр савабын бирсен, иманнарын ахирәт сәфәрендә юлдаш кылсын, тереләр арасында аларнын исемнәре мәнге данлы булсын.

**Рафаэль-хазрәт МАНЮРОВ,**
*Мордовия Республикасында Россия Федерациясе мөселманнарынын Үзәк диния нәзарәте тулы хокуклы вәкиле*